
# Казан – Татарстан башкаласы


Тихонов Олег һәм Багров Иван 11»А»

**Казан** (рус. *Казань*) – Татарстан Республикасыны башкаласың, Русиянең икътисади, мәдәни, сәяси үзәкләренең берсе. Иделнең сул ягында, аңа Казансу кушылу урынында урнашкан зур порт.



# Казан флагы һәм гербы





Шәһәрнең теркәлгән «Русиянең өченче башкаласы» бренды бар, шулай ук ярымрәсми рәвештә ул «Русия федерализмы үзәге (башкаласы)» һәм «бөтендөнья татарларының башкаласы» дип атала. 2005 елда Казан шәһәре 1000-еллыгын бәйрәм итте, 2013 елда Казанда XXVII Җәйге Универсиада узды. 2015 елда — су спорт төрләре буенча Дөнья чемпионаты үткәрелде, ә 2018 елда шәһәр (Русиянең башка шәһәрләр белән) ФИФА Дөнья футбол чемпионатын кабул итә.



# Урынлаштыру

Иделнең сул ягында, аңа Казансу кушылу төшендә урнашкан. Географик координатлар («ноленче» километр): 55°47′ т. к. 49°06′ кч. о.[HGЯO]. Тирәнлек: 29 км, киңлек: 31 км. Шәһәрнең сәгать поясы — UTC+4, ләкин мәскәү вакыты.

Шәһәр көнбатыш, үзәк һәм көньяк-көнбатыш өлешләрендә Идел елгасына чыга, яр буе сызыгы — 15 километр. Казанның көнбатыш читендә Идел аша күпер бар. Казансу елгасы төньяк-көнчыгыштан көнбатышка ага һәм шәһәрне ике тиң диярлек өлешкә бүлә. Казансу аша биш күпер вә дамба төзелгән, шулай ук елга астында Казан метрополитенының Үзәк сызыгы бара.



# Климат

Шәһәрнең климаты - уртача континенталь, суыклар һәм корылык еш очрашмыйлар. Казанга күбрәк көньяк һәм көнчыгыш җилләр өрә, җилсез һава уртача елда 13 тапкыр була. Кар капламы февраль һәм март айларында якынча 38 см. Иң салкын ай - гыйнвар (−11,6 °C), иң эссе - июль (19,7 °C), уртача еллык явым-төшем күләме – 550 мм. Иң яңгырлы ай – июнь (70 мм), ә иң аз санда явым-төшем мартта – 25 мм. 2010 елның 1 августында Казанда температур максимум - 39,0 °C теркәлгән. Минимум - 1942 елның 21 гыйнварендә (−46,8 °C) булган. Елда уртача җил көче 3,6 м/с була, ә һава дымлылыгы — 75 %.

**Казан климаты**

| Күрсәткеч | Гый | Фев | Мар | Апр | Май | Июн | Июл | Авг | Сен | Окт | Ноя | Дек |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Абсолют максимум, °C | 3,8 | 5,2 | 14,0 | 29,5 | 33,8 | 37,5 | 38,9 | 39,0 | 32,3 | 23,4 | 15,0 | 6,1 |
| Уртача максимум, °C | −7,2 | −6,7 | −0,2 | 10,2 | 19,0 | 23,5 | 25,5 | 22,9 | 16,3 | 8,1 | −1 | −5,8 |
| Уртача температура, °C | −10,4 | −10,2 | −4 | 5,5 | 13,3 | 18,1 | 20,2 | 17,6 | 11,7 | 4,8 | −3,4 | −8,5 |
| Уртача минимум, °C | −13,5 | −13,3 | −7,3 | 1,6 | 8,2 | 13,3 | 15,5 | 13,3 | 8,2 | 2,2 | −5,6 | −11,4 |
| Абсолют минимум, °C | −46,8 | −39,9 | −31,7 | −25,6 | −6,5 | −1,4 | 2,6 | 1,6 | −5,4 | −23,4 | −36,6 | −43,9 |
| Явым-төшем нормасы, мм | 40 | 33 | 32 | 31 | 41 | 63 | 65 | 60 | 51 | 53 | 46 | 43 |

# Халык


Казан шәһәренең халык саны – 1,143 млн кеше, шәһәр мәйданы – 425,3 км².

## Милли состав

Казан – күпмилләтле шәһәр. Монда татарлар, руслар, чуашлар һ. б. милләтләр яши. Башкалада татарлар һәм урысларның саны якынча берүк (татарлар 47,6%, урыслар 48,6% ). Өченче урында Республикадагы кебек үк чуашлар, 4-5 урыннарда украиннар һәм әзериләр тора.

## Дин

Казанда төрле дин вәкилләре яши. Мөселманнар һәм православ христианнар күпчелекне тәшкил итә. Шулай ук католиклар (*кара*: Казан католик гыйбадәтханәсе), яһүдиләр (*кара*: Казан синагогасы), лютераннар (*кара*: Казан кирхасы), староверлар (*кара*: Покрау чиркәве) һ. б. дин вәкилләре бар.





# Шәһәр исеме

**Казан исеме барлыкка килүе хакында бик күп версияләр һәм риваятьләр бар:**
1) "Казан" сүзеннән (котёл). Риваять буенча, хан үз хезмәтчесен су алырга җибәргән. Хезмәтче су алганда алтын казанны елгага төшергән. Шуннан соң елганы да, шәһәрне дә Казан дип йөртә башлаганнар.
2) Кайсыбер кешеләр елга исеме "каз" сүзеннән чыккан диләр. Аларның фикеренчә, борынгы заманларда елга янында казлар яшәгәннәр. Шуннан елгага Казан суы исеме бирелгән, соңыннан шәһәргә дә исем күчкән.
3) Башкорт филологы Җ. Киекбаев сүзләренчә, Казан исеме "каен" сүзеннән килә. Мәсәлән, Башкортстанда Казанлы исемле авыл бар. Киекбаев фикеренчә, бу исем элек Каенлы булган (авыл каеннар урманы эчендә тора).
4) Хәсән хан исеменнән.



# Төнге Казан. Кремль күренеше



# Муса Җәлил һәм аның көрәштәшләренә куелган һәйкәл.



# Азак!

